античное, древнетюркское и русское словесное искусство, о том, что ни русская, ни татарская литература в своём многовековом существовании не находились в изоляции, более того, взаимодействовали, перенимали темы, идеи, имели некие сквозные мотивы, общечеловеческие ценности.

## ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ ЖУРНАЛИСТИКА МАТЕРИАЛЛАРЫН КАБУЛ ИТҮГӘ ЯСАГАН ТӘЭСИРЕ

***Резеда Локман кызы Зәйни,***
*Казан федераль университеты доценты,*
*филология фәннәре кандидаты*

Бүгенге көн журналистикасы беренче чиратта сүз белән түгел, сурәт белән эшләүгә күчеп бара. Элегрәк, әле газета белән журналдан кала башка гаммәви мәгълүмат чаралары булмаган чорда, журналист үзенең хәбәрен, әйтәсе килгән фикерен укучыга җиткерер өчен сүз белән эшләү сәләтен, тәҗрибәсен эшкә җиккән. Ә хәзер аңа радио-телевидениеда гына түгел, интернетта да, матбугатта да (аның да интернет вариантлары бар бит) үзенә тартып торырлык фотосурәтләр, видеоязмалар, инфографика, дизайн элементларына игътибарны юнәлтергә туры килә. Ә ГМЧның интернет вариантларына исә тулаем мультимедиалылык хас.

Монда ике төрле күренешне күзәтергә мөмкин. Бер төркем журналистлар, шул визуаль контентның барлык мөмкинлекләрен эшкә җигеп, язма текстының камиллегенә ирешергә кирәклеген бөтенләй дә онытып җибәрәләр. Ә икенче берләре, боларына басмаларның кәгазь вариантлары чыгып торганнары кирә, газетаның интернетта электрон варианты булуына игътибар да итмичә, визуаль контентны бөтенләй дә исәптән төшерәләр. Замана таләпләренә туры килер өчен алтын урталыкны табу бүгенге көндә аеруча мөһим.

Хезмәтебезнең максаты: гаммәви мәгълүмат чараларындагы визуаль контентның журналист материалларына ясаган тәэсирен ачыклау, татар журналистикасына җитешмәгән якларын билгеләү.

Нәрсә соң ул визуаль контент? Ул – тексттан кала, аның белән янәшә килә торган калган барлык мәгълүмат. Фотосурәтләр, рәсем, карикатура, логотип, схема, график, диаграммалар, шулай ук слайд-

шоу, анимация, клип, видеоязмалар текстны кабул итүне җиңеләйтә, ә кайбер чакта аны алыштырып та килә. А.А.Градюшко әйтүенчә, бүген укый торган кеше чорын мәгълүматны визуальләштерү гасыры алмаштыра. [1, 79 б.]

Монда аудиторияне ялкаулыкта, текстны укырга теләмәүдә гаепләү дә дөрес түгелдер. Әйе, визуаль мәгълүматны кабул итәргә җиңел, өстәмә көч куясы да түгел. Әмма андый мәгълүматка ихтыяҗ, беренчедән, вакытның бик тиз агышына, эш-мәшәкатьләр күплеккә, кешенең аз вакыт эчендә күләмле мәгълүмат алырга омтылуына бәйле; икенчедән, бүгенге заманда аудитория кеше, вакыйга, очрак турында "тере" мәгълүмат алырга тели, аның сораулары күп туа, аның шул вакыйгаларның шаһите буласы килә. Ә визуаль мәгълүмат нәкъ шул шаһит була алу мөмкинлеген тудыра да.

Нәкъ менә шуңа да бүгенге көн аудиториясе басма вакытлы матбугатны телевизор карау яки интернеттагы социаль челтәрләрдә бирелгән мәгълүмат белән танышуга алыштыра. Чөнки аларда мультимедиалылыкның барлык мөмкинлекләре дә файдаланыла бит.

Журналистика галимнәре һәм практиклары мультимедиа төшенчәсен бүген башкача атый, инглиз теленнән алынган visual storytelling сүзтезмәсе, ягъни визуаль сторителлинг (сөйләп бирү, хикәяләштерү) белән алыштыра. Бу текстсыз гына, сурәт белән дә сөйләп бирү дигәнне аңлата.

Элегрәк "сүз белән сурәт ясау" дисәләр, бүген моны үзгәртеп, "сурәттән сүз ясау", ягъни визуаль контент ярдәмендә аудитория кабул итәрлек текст тудыру дип аңларга була.

Татар журналистикасында "сурәттән сүз ясау" нинди рәвештә бара соң?

Әлбәттә, визуаль контент ул журналистика өчен яңа күренеш түгел, XX гасырның башында барлыкка килгән татарча сатирик журналларда, мәсәлән, карикатуралар актив кулланылган. 20-30нчы еллардан газета-журналларда күпләп фотолар басылган. Әле газета полосасы типографияләрдә кул белән буяуга батып җыелган вакытларда ук кайбер игътибарга лаек фикерләр, абзацлар аерым график элементлар ярдәмендә аерып бирелгән. Бу традицияләр бүгенге көндә дә дәвам ителә.

Әмма еш кына хәтта шул традицион чаралар да бар куәтенә файдаланылмый. Мәсәлән, газетаның басма вариантында

бастырылган язманы автоматик рәвештә генә сайтка күчереп куйганда, газета битендә кулланылган бердәнбер фото да шул язма янында урын ала. Һәм шуның белән бетте. Ә бит интернет бите газета мәйданы кебек чикле түгел, анда бер генә түгел, темага туры килгән ун фото да кулланырга мөмкин. Әмма татар газета редакцияләре бу мөмкинлекне кулдан ычкындыра. Әле бит сайтка куелган ул фотоны зурайтып булырга да тиеш, фотода сүрәтләнгән кешеләр, биналар, әйләнә-тирәне зурайтып карап, укучы әллә никадәр өстәмә мәгълүмат таба алган булыр иде. Кызганыч, татар газеталары сайтларында бу моментка да игътибар юк, фотоларны теләгән кадәр зурайтып булмый, зурайткан очракта да ул фотоның сыйфаты кимү хисабына гына зурайтыла.

Журналист материалы ул хәбәр итү генә түгел, ул авторның кичерешләре, хисләре, мөнәсәбәте, әдәби образлар, хисси детальләр дә дигән сүз бит. Менә шуларны җиткерүдә тел чаралары гына түгел, визуаль контент та ярдәмгә килә ала.

Татарча чыга торган матбугат чараларының сайтларын күзәтү шундый нәтиҗәгә китерә: күп очракта сайтларында басма вариантның язмалары гына күчерелеп бирелә. Дөрес, басма вариантны яздырып укучылар кимемәсен өчен, барлык материалларны да күчермиләр. Монысы аңлашыла да. Басма вариантлар да бетәргә тиеш түгел. Хәтта интернетлашу бездән күпкә алданрак башланган АКШта, Көнбатыш Европада да газета-журналларның гомуми тиражының өчтән берен басма вариант тәшкил итә. Чөнки реклама бирүчеләрне күбрәк басма вариант үзенә тарта, ышаныч тудыра. Бездә дә басма газета-журналлар чыгуын дәвам итсен иде. Әмма бөтен көчне басмасына гына биреп, интернет вариантлары яңа технология мөмкинлекләрен файдаланмаса, бу газетаның гомумән киләчәге булмаска да мөмкин. Укучыга сайлап алып укыр өчен офыклар киң бит бүген, гел татарчаны гына укыйм дип тә тормый ул, чөнки рус телен дә яхшы белә. Әгәр кабул итәргә җиңелрәк икән, ул бик җиңел генә рус телле газеталарның сайтларына һәм кәгазь вариантларына да күчәчәк. Татар газеталарын уку бары тик теле бетмәсен дип җан аткан милләттәшләргә генә кайтып калса, киләчәкне фаразлау да куркыныч.

Татар газеталарының сайтларына керү хәтта татар телен начар белүчеләр өчен ихтыяҗ дәрәҗәсенә менәргә тиеш. Сайттагы мәгълүматның күплеге, кабул итәргә уңайлылыгы, визуаль

контентның җитәрлек булуы татарчасы чамалыларны да шул сайтка тартып торыр иде. Параллель үткәрик: инглиз телен бик яхшы белеп бетермәсәләр дә, инглиз телле сайтларның кабул итү өчен бик уңайлыларын, нәкъ шул визуаль контент яхшы куелганнарын карап чыгучылар күп, алар телне белмим дип тормыйлар, булган график элементлар ярдәмендә мәгънәне аңларга омтылалар. Һәм бу килеп тә чыга, визуаль сторителлинг үз дигәненә ирешә, инглиз телен яхшы белмәгән очракта да фикернең күп өлеше аңлашыла. Татар телле газета сайтларын да шулай телне яхшы белмәүчеләрне дә үзенә тартырлык итеп оештырасы иде ул.

Татар журналистлары, татар басмаларының редакторлары, хәтта басма газета өчен эшләгән очракта да, үзләренең глобаль медиакиңлектә, күпчелек чаралары цифрлы форматка күчеп баручы медиакиңлектә эшләүләрен онытмаска тиешләр.

**Әдәбият**

1. Градюшко А.А. Перспективные стратегии веб-журналистики в глобальном информационном пространстве // Международная журналистика-2014: диалог культур и взаимодействие медиа разных стран : материалы Третьей Междунар. науч.-практ. конф., 20 февр. 2014 г., Минск. — Минск, 2014. — С. 77-89.

2. Симакова С.И. Влияние новых технологий на визуальный контент журналистских материалов // Вестник Челябинского государственного университета. Филология. Искусствоведение. Вып.94. – 2015. - №5 (360). – С.163-169.

## ӘХМӘТЗӘКИ ВӘЛИДИҘЕҢ КӨРӘШТӘШТӘРЕ

***Азалина Ильгиз ҡыҙы Ишкина,***
*М.Аҡмулла исемендәге башҡорт*
*дәүләт педагогия университетының 2се курс студенты*
*Җитәкче:* ***Зөләйхә Әхмәт ҡыҙы Хәбибуллина,***
*доцент*

Халҡыбыҙҙың бөтә ғүмерен, эшсәнлеген милләтенә хеҙмәт итеүгә бағышлаған шәхестәре күп. Был яҡтан ул бүтәндәргә үрнәк булған данлыҡлы улдары менән хаҡлы рәүештә ғорурлана. Әхмәтзәки Вәлиди һәм уның көрәштәштәре шундай яҡты